# Дәрес-практикум:
# « Процентка мәсьәләләр чишү»

Проблема

«Тарту ник зарарлы?»

Укытучы: Хәбибуллина Фәния Гаделша кызы

дале
е

- Дәреснең максаты
- Телдән исәпләү
- Проблемалы сораулар
- Мәсьәләләр чишү
- Кызыклы-файдалы
- Йомгаклау

назад

далее

# Дәрес максаты:

- Үстерешле: процентлар исәпләүгә кызыксыну тәрбияләү, танып белү активлыгын үстерү;
- *Белем бирү:* «Процентлар» темасын үзләштерүдә укучыларның шәхси фикерен актуальләштерү , тема буенча белемнәрне ныгыту .
- *Тәрбияви:* практик мәсьәләләр чишкәндә зарарлы гадәтләр проблемасын ачу.

главная

далее

# Игътибар:

**«Тәмәке тәнгә зарар бирә, акылны ала, тулы бер милләтне надан калдыра »**

**О. Бальзак**



главная

далее

# Дәрес барышы:

**Телдән исәплибез:**

Укып процентларда күрсәтергә:

0,01; 0,5; 0,23; ½; 0,94;. 1,01; 2/5; 1/25;, ¾; 0,017.

Процентны вакланма аша күрсәтергә:

13%. 4%. 67%, 112%. 0,3%, 50%, 300%

главная

далее

# Проблема.

- 1.Барлык агулы матдәләр кеше организ-мына тискәре тәэсир итә.Тәмәкечеләр төрле авырулардан интегә. Ниндиләрдән?
- ¨ Ни өчен кешеләр барыбер тарта? Кайчан тарта башлыйлар?. Билгеле, яшүсмер чакта.

главная

далее

# Белү файдалы:

- *-Тартучылар гаил*әсендә туган сабыйлар салкынга 4-5 тапкыр тизрәк бирешүчән, хроник авырудан интегүчеләр.
- *Күп илдә хезмәт урынында тарту тыела. Җитди эш бирүче тартучына эшкә алмаска яки азат итәргә* мөмкин.



главная

далее



# Мәсьәләләр

1. Иң зарарлы матдәләрнең % билгеләргә:

- Әгәр бер сигаретта 2% никотин, синиль кислотасы никотинның 1/2е, тәмәке дегете никотиннан 7,5 тапкыр күбрәк, углерод оксиды тәмәке дегетенең 3/5 ен, полоний углерод оксидының 2/3 сен тәшкил итсә, ничә %?

# Статистика:

- Малайлар- 60% ы, ә
- Кызлар – 40% тартуы билгеле.
- Безнең мәктәптә- 19 малай, 36 кыз булса ничә тартучы укучы булыр икән?

главная

далее

- Проблемалы
- Сорауларны
- Чишү

главная

далее

# Тартучы бала гомерен 15% кыскарта.

- Россиядә уртача гомер озынлыгы 56 ел булса, тартучы баланың гомер озынлыгын исәпләргә.

главная

далее

# Ата – ана тартса, яңа туган нарасый авырлыгын исәплик.

- Яңа туган сабый якынча 3кг 300г.Әгәр әтисе тартса- ул 125г кимрәк туа. Әгәр әнисе дә тартса 300г кимрәк туа. Әгәр әтисе тартса бала кичә% авырлыгын югалта? Ә әнисе? Җавапны берәмлекләргә кадәр түгәрәкләргә.

главн
ая

далее

- Әгәр яхшы секретарь-машинистка тартса, 800 тамга сукканда 4% хата була. Ул ничә хата җибәрер?

главная

далее

# Нәтиҗәләр:

- Әгәр тәмәке тарту кеше гомерен кыскартуы исбатланган икән, тарта башлау *кирәкме?*

- Бөтен кешелек дөньясы тарту модада түгел, эстетик яктан да матурлыгы юк, сәламәтлеккә дә зарарлы дип саный.Бәлки кемдер файдалы ягын күрсәтер?

главная

далее



# Йомгаклау:

- Өй эше:
- Мәсьәлә.

- 1. Әгәр кеше тәүлеккә бер пачка сигарет тартса, (бер пачка-15 сум) айга 4500 сум хезмәт хакы алучының елга күпме табышы юкка чыга (айда-30, елда -365 көн)?
- 2. *Машинистка 4 көндә 80 бит басарга тиеш иде. Беренче ике көндә ул эшнең 45% башкарды, өченче көндә беренче ике көннән 20% ка кимрәк басты. Дүртенче көнгә басу өчен ничә бит калган?*

главная

На начало

# Синквейн «Мин»

- 1 нче юл – теманы бер сүз белән әйтергә, сүз төркеме буларак исем яки зат алмашлыгы
- 2 нче юл – теманы ике сүз белән әйтергә, сыйфат булсын (ике сыйфат)
- 3 нче юл – тема кысаларында хәрәкәтне күрсәтә торган өч фигыль әйтергә
- 4 нче юл – синең темага мөнәсәбәтеңне белдерүче дүрт сүз
- 5 нче юл – беренче юлның синонимы, нинди сүз төркеме булса да ярый

# Фикердәшләрне тыңлыйк

- Сәламәтлек
- Нык, исән, таза, сау, һ.б.
- Шөгыльләнү, сикерү, йөгерү
- Мин сәламәтлегемне һәрчак кайгыртам
- Саулык, (исәнлек), һ.б.